Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 март 2019 ел №286

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында»гы 2006 елның 3 февралендәге № 37 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге № 217-ФЗ Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен тикшереп торуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы № 307-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендәге № 382-ФЗ, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланучы вазифаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2018 елның 22 декабрендәге № 113-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмә хакында» гы 2006 елның 3 февралендәге № 37 карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 4 июлендәге №306, 2015 елның 13 мартындагы № 455, 2015 елның 10 декабрендәге № 40, 2017 елның 27 июлендәге № 191, 2018 елның 11 маендагы № 240 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә депутат үз эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Әлмәт муниципаль районы җирле

үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул итү хокукына ия.»;

1.2. 19 статьяның 3 өлешендәге 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюзда катнашудан тыш, съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашу очрагыннан тыш; муниципаль берәмлекнең идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган оешмалар яисә идарә итүне гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә (устав капиталында катнашу өлешләре) тәкъдир итү; федераль законнарда каралган башка очракларда;".

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга).

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И. Р.).

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин